КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 14 ноябрь г.Казань № 999

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 17 декабрь, 1157 нче; 2021 ел, 19 февраль, 88 нче; 2021 ел, 8 декабрь, 1205 нче; 2022 ел, 14 февраль, 128 нче; 2022 ел, 1 август, 744 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1499 нчы; 2023 ел, 20 апрель, 499 нчы; 2024 ел, 16 февраль, 88 нче; 2024 ел, 4 июль, 508 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә (механизмга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.
2. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 14 ноябрь, 999 нчы
карары редакциясендә)

# Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

## I. Субсидия бирү турында гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нче карарының 1 пунктында күрсәтелгән яңа туган балалы гаиләләр категорияләрен балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча «Яңа туган балага бүләк» акциясен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – яңа туган балалы гаиләләр, бүләк комплекты, коммерциягә карамаган оешмалар, субсидия) бирү максатларын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Субсидия бирүнең максаты – Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен (алга таба – «Яңа туган балага бүләк» акциясе) гамәлгә ашыру кысаларында яңа туган балалы гаиләләрне бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча коммерциягә карамаган оешмаларның чыгымнарын финанс белән тәэмин итү.

1.3. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатка каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – бюджет акчасын алучы буларак Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә тиешле финанс елына һәм план чорына субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә

җиткерелгән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Вәкаләтле орган).

1.4. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

1.5. Субсидия Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуда катнашу өчен коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) сорау юлы белән үткәрелә торган сайлап алу (алга таба – сайлап алу) нәтиҗәләре буенча, коммерциягә карамаган оешмаларның сайлап алу критерийларына туры килү-килмәвеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып бирелә.

Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

бүләк комплектларын булдыру өчен балалар кирәк-яракларын сатып алу һәм саклау;

бүләк комплектларын балалар кирәк-яраклары белән комплектлау һәм аларны яңа туган балалы гаиләләргә тапшыру урынына кадәр илтеп бирү;

яңа туган балалы гаиләләрне бүләк комплектлары белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга кирәкле хезмәтләр һәм эшләр өченче затлар тарафыннан күрсәтелгән һәм башкарылган өчен түләү;

салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәре турында Россия Федерациясе законнары нигезендә коммерциягә карамаган оешмаларның салымнарын, җыемнарын, иминият кертемнәрен һәм башка мәҗбүри түләүләрен түләү.

1.6. Вәкаләтле органның коммерциягә карамаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) электрон рәвештәге документларны кулланып гамәлгә ашырыла.

## II. Субсидия бирүнең шартлары

2.1. Заявканы карап тикшерү һәм субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү даталарына карата коммерциягә карамаган оешма түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

коммерциягә карамаган оешма чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами

(шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

коммерциягә карамаган оешма экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

коммерциягә карамаган оешма БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

коммерциягә карамаган оешма әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

коммерциягә карамаган оешма «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

коммерциягә карамаган оешманың бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы юк яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

коммерциягә карамаган оешманың башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

коммерциягә карамаган оешма үзгәртеп оештыру (коммерциягә карамаган оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки икоммерциягә карамаган оешманың баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар юк.

2.2. Коммерциягә карамаган оешма түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

сәяси партия һәм хәрәкәт формасындагы оешма булып тормаска;

дәүләт учреждениесе яки муниципаль учреждение һәм һөнәри берлек булып тормаска;

Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмияткә ия эшчәнлек алып барырга, шул исәптән балалары булган аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән социаль әһәмиятле проектларны юридик зат буларак кимендә өч ел дәвамында гамәлгә ашырырга.

2.3. Коммерциягә карамаган оешманың субсидия күләме ($Р_{суб}$) заявканы теркәүгә алганда бирелгән тәртип номеры нигезендә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Р_{суб} = К_{пк} \times С_{пк},$$

монда:

$К_{пк}$ – заявкада күрсәтелгән бүләк комплектлары саны;

$С_{пк}$ – ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган бер бүләк комплектының кыйммәте.

Субсидия сайлап алуда җиңүчеләр арасында сайлап алу таләпләренә туры килүенә һәм заявкалар керү чиратына карап бүленә.

2.4. Субсидия бирү шарты – әлеге Тәртипнең V бүлегендә каралган тәртиптә Вәкаләтле органның субсидия алучыга субсидия бирү турындагы карары нигезендә субсидия бирү турында килешү төзү һәм субсидия алучының, субсидия алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләре һәм устав (тупланма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында җәмгыятьләрдән, устав (тупланма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның аларга карата Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүне гамәлгә ашыруга һәм мондый нигезләмәләрне субсидия бирү турындагы килешүгә кертүгә ризалыгы.

## III. Сайлап алуны үткәрү тәртибе

3.1. Сайлап алу Вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасында гамәлгә ашырыла. «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурадагы идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

3.2. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү, Вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формалары тутырылып, электрон рәвештә булдырыла, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырып чыгарыла.

3.3. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган һәм бердәм порталында субсидия турында мәгълүмат бастырып чыгарылганнан соң, «Электрон бюджет» системасында белдерү булдырылган көннән

алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле орган тарафыннан урнаштырыла.

Сайлап алу агымдагы финанс елы дәвамында, әмма сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән датадан соң гына үткәрелә.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы, шул ук вакытта заявкаларны кабул итүнең тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 6.1 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

коммерциягә карамаган оешмаларга карата әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә билгеләнгән, коммерциягә карамаган оешмалар әлеге Тәртиптә билгеләнгән датага туры килергә тиеш булган таләпләр һәм әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

сайлап алу критерийлары;

заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 3.4 – 3.6 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләр билгеләнә торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Тәртипнең 3.13 һәм 3.14 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук әлеге Тәртипнең 3.15 пункты нигезендә аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләп чыгару тәртибе, сайлап алу нәтиҗәләре буенча сайлап алуда җиңүчегә бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә ала алган субсидия бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәгәлләнү датасы;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә имза куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен

урнаштыру сроклары (алар сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 нче календарь көннән дә соңрак була алмый).

3.4. Субсидия алу максаты белән сайлап алуда катнашу өчен коммерциягә карамаган оешмалар «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру һәм «Электрон бюджет» системасына сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә каралган документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь документлар) кертү юлы белән электрон формада заявка формалаштыра (алга таба – электрон формага күчерелгән документлар).

3.5. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) коммерциягә карамаган оешма турында мәгълүмат:

тулы һәм кыскартылган исеме;

салым түләүченең идентификация номеры;

төп дәүләт теркәү номеры;

салым органында исәпкә куелу сәбәбе датасы һәм коды

дәүләт теркәвенә алу датасы;

коммерциягә карамаган оешманың адресы;

элемтәгә керү өчен телефон номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

җитәкче турында белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), вазыйфасы, телефоны);

баш бухгалтер турында белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), вазыйфасы, телефоны) (булганда);

коммерциягә карамаган оешманың веб-сайты, социаль челтәрләре (булганда);

субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә ачылган счетлар турында, шулай ук субсидия бирү турындагы килешүгә имза куярга вәкаләт бирелгән зат турында мәгълүмат;

һәр социаль әһәмиятле чарада катнашучылар санын күрсәтеп, соңгы өч ел өчен коммерциягә карамаган оешма эшчәнлеге турында, шул исәптән балалары булган аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән, гамәлгә ашырыла торган социаль әһәмиятле проектлар турында мәгълүмат;

Татарстан Республикасы территориясендә заявка бирелә торган елга кадәрге елда яңа туган балалы гаиләләрне бүләк комплектлары белән тәэмин итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында мәгълүмат;

массакүләм мәгълүмат чараларында басманың (мәкаләләр, видеосюжетлар, радиоэфирлар һ.б.) интернет чыганакларына сылтамалар (булганда);

б) электрон формага күчерелгән түбәндәге документлар:

планлаштырыла торган чыгымнар күләменең нигезләүләре бирелгән, коммериягә карамаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган, мөһер (булганда) белән беркетелгән субсидия күләменең исәп-хисабы;

гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы документларның коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан имза куелган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән күчермәләре;

коммериягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан кул куелган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән коммериягә карамаган оешманың штат расписаниесе;

коммериягә карамаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан расланган (имза куелган) һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән коммериягә карамаган оешманың агымдагы елга керемнәр һәм чыгымнар сметасы;

коммериягә карамаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имза куелган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән узган финанс елы өчен бухгалтерлык балансы;

коммериягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан имза куелган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән агымдагы елга эшләрнең календарь планы (шул исәптән социаль әһәмияткә ия чаралар исемлеге);

яңа туган балалы гаиләләрне бүләк комплектлары белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага кирәкле эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен өченче затлар белән төзелгән, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан кул куелган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән шартнамәләр;

в) коммериягә карамаган оешма тарафыннан тәкъдим ителә торган субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләре.

Заявкадагы мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны үз вакытында бирү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә коммерциягә карамаган оешмалар җавап бирә.

Заявкага кертелә торган электрон формадагы документлар киң кулланышта булган, документны тулысынча яисә аның бер фрагментын мәгълүмат карау өчен билгеләнгән гомумфайдаланудагы программа тәэминаты чаралары белән карау мөмкинлеге тәэмин ителә торган ачык форматларда булырга тиеш һәм махсус программа яки технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышып булмый торган чаралар белән сакланган яки шифрланган булмаска тиеш.

3.6. Заявка коммерциягә карамаган оешма җитәкчесенең яки ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

3.7. Коммерциягә карамаган оешмалар, бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән һәм заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле органга «Электрон бюджет» системасында тиешле рәсми сорау булдыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен аңлату хакында рәсми сорау җибәрергә хокуклы.

Вәкаләтле орган, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сорауга җавап итеп, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән срок эчендә, әмма заявкалар бирү тәмамланганга кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча, тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә бирелгән аңлатма сайлап алуны үткәрү турында белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртмәскә тиеш.

«Электрон бюджет» системасында әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә формалаштырыла торган аңлатмадан файдалану мөмкинлеге барлык коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә.

3.8. Заявкалар кабул итү срогы чыкканга кадәр коммерциягә карамаган оешма ирекле рәвештә язылган гариза буенча, шул исәптән заявкага үзгәрешләр кертү һәм яңа заявка бирү максаты белән заявканы кире алырга хокуклы.

Коммерциягә карамаган оешма заявкага (шул исәптән аны эшләп бетерүгә) һәм

(яки) заявка белән тапшырылган, электрон формага күчерелгән документларга «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән һәм (яки) электрон формага күчерелгән документларны «Электрон бюджет» системасына кертү юлы белән үзгәрешләр кертә.

Заявкага үзгәрешләр кертү яисә заявканы кире алу турында карар коммерциягә карамаган оешма тарафыннан мөстәкыйль кабул ителә.

Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан заявкага кертелгән үзгәреш (шул исәптән аны эшләп бетерү) яки коммерциягә карамаган оешма тарафыннан аны кире алу турында хәбәрнамә, әгәр аңа үзгәреш кертү (эшләп бетерү) коммерциягә карамаган оешма тарафыннан яңа заявка бирү юлы белән гамәлгә ашырылган яки аны кире алу турындагы хәбәрнамә Вәкаләтле орган тарафыннан заявкалар бирү срогы чыкканга кадәр алынган булса, гамәлдә була.

Коммерциягә карамаган оешмалар бер генә заявка бирергә мөмкин.

3.9. Тиешле финанс елына әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатка каралган субсидияләрне бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары Вәкаләтле органга арттырылган, сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тартылган, субсидия алучы белән субсидия бирү турында килешү өзелгән очракларда, Вәкаләтле орган, әлеге Тәртип нигезләмәләренә таянып, өстәмә сайлап алуны үткәрү турында карар кабул итәргә мөмкин.

3.10. Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан заявка бирү датасы булып, «Электрон бюджет» системасында заявкага теркәлү номеры бирелеп, әлеге заявкага коммерциягә карамаган оешма тарафыннан имза куелган көн санала.

3.11. Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле органга «Электрон бюджет» системасында коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан тапшырган заявкаларга аларны карау өчен керү мөмкинлеге бирелә.

3.12. Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аңа имза куелган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

Заявкаларны ачу беркетмәсендә сайлап алуда катнашуга кергән заявкаларда түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

заявканы теркәү номеры;

заявка керү датасы һәм вакыты;

коммерциягә карамаган оешманың тулы исеме;

коммерциягә карамаган оешманың адресы.

3.13. Заявка һәм документлар Вәкаләтле орган тарафыннан заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән алып 10 эш көне эчендә аларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә һәм әлеге Тәртипнең 3.5 пунктында каралган таләпләргә туры килү-килмәве карап тикшерелә.

Коммерциягә карамаган оешманы әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү дәүләт мәгълүмат системалары мәгълүматлары нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең

бердәм системасыннан файдаланып (техник мөмкинлек булганда), «Электрон бюджет» системасында автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле орган, ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Вәкаләтле органның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта, коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуксыз (әгәр коммерциягә карамаган оешма әлеге документларны һәм мәгълүматны Вәкаләтле органга үз инициативасы белән тапшырырга әзер булган очрактан тыш).

«Электрон бюджет» системасында автомат тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта, коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау коммерциягә карамаган оешма тарафыннан «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән әлеге таләпләргә туры килү-килмәү турында электрон рәвештә тамгалар кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

Кергән заявкалар, заявкаларның керү чираты карап, рангларга бүленә.

3.14. Әгәр заявка сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм заявканы кабул итмәү өчен нигезләр булмаганда, ул дөрес дип таныла.

3.15. Заявканы карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итүмәү өчен нигезләр:

коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган заявканың һәм (яки) документларның әлеге Тәртиптә каралган, сайлап алу турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатларында, коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

заявканың коммерциягә карамаган оешма тарафыннан аларны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң тапшырылуы.

3.16. Заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе бердәм порталда заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре нигезендә автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган җитәкчесенең яки ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аңа имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

3.17. Сайлап алу түбәндәге очракларда үткәрелмәгән дип таныла:

а) заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

б) заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

3.18. Сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) билгеләү нәтиҗәләре нигезендә

бердәм порталда автомат рәвештә сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе булдырыла, аңа «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган җитәкчесе яки ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза куела һәм, аңа имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә түбәндәге белешмәләр кертелә:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат (аларны кабул итмәү сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

субсидия бирү турында килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе шулай ук Вәкаләтле орган тарафыннан Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 нче календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

3.19. Вәкаләтле орган «Электрон бюджет» системасында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе урнаштырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3.20. Субсидия алучыга (алучыларга) субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында каралган сайлап алу критерийларына туры килмәү;

субсидия алучы (алучылар) тарафыннан тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 3.5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү яки әлеге документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

субсидия алучы (алучылар) тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес булмау факты билгеләнү.

## IV. Сайлап алуны үткәрмәү

4.1. Вәкаләтле орган, әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары Вәкаләтле органга киметелгән (кире алынган) очракта, сайлап алуны үткәрмәскә хокуклы.

Бердәм порталда Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуны үткәрмәү турында белдерү коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланган датага кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

4.2. Сайлап алуны үткәрмәү турында белдерү «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә булдырыла, Вәкаләтле орган җитәкчесенең яки ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла

һәм сайлап алуны үткәрмәү сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

4.3. Заявкалар биргән коммерциягә карамаган оешмаларга «Электрон бюджет» системасы аша сайлап алуны үткәрмәү турында мәгълүмат бирелә.

4.4. Сайлап алу, бердәм порталда сайлап алуны үткәрмәү турында белдерү урнаштырылган көннән алып, уздырылмый дип санала.

4.5. Әлеге Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә сайлап алуны үткәрмәү срогы тәмамланганнан соң һәм сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) белән субсидия бирү турында килешү төзелгәнгә кадәр Вәкаләтле орган Россия Федерациясе Граждан кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көчтәге шартлар барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны уздырмаска мөмкин.

## V. Вәкаләтле органның сайлап алуны үткәрү нәтиҗәләре буенча сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе

5.1. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле орган һәм сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) арасында, Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 20нче эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә субсидия бирү турында килешү төзелә.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Субсидия бирү турындагы килешүгә элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Вәкаләтле органга киметелгән очракта, субсидия алучы белән субсидия бирү турындагы килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән килешеп булмаганда субсидия бирү турындагы килешүне өзү хакында, субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт кертелә.

Бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары Вәкаләтле органга субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган итеп киметелгән очракта, субсидия бирү турындагы килешүгә субсидия бирү турындагы килешүнең яңа шартларын килештерү карала торган өстәмә килешү яки, яңа шартлар буенча бер фикергә ирешеп булмаганда, субсидия бирү турындагы килешүне өзү турында өстәмә килешү төзелә.

Вәкаләтле орган, кирәк булганда, субсидия алучы (алучылар) белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән субсидия бирү турындагы килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

5.2. Субсидия алучы (алучылар) «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында килешү формалаштырылган көннән алып биш эш көне эчендә субсидия бирү турындагы килешүгә «Электрон бюджет» системасы аша субсидия алучы (алучылар) исеменнән эш итәргә хокуклы булган затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза куярга тиеш.

Әгәр субсидия алучы (алучылар) тарафыннан әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокта «Электрон бюджет» системасы аша субсидия бирү турындагы килешүгә имза куелмаган булса, субсидия алучы (алучылар) субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан дип санала.

Субсидия алучы (алучылар) тарафыннан субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тартылган, субсидия алучы (алучылар) белән субсидия бирү турында килешү өзелгән һәм, агымдагы елда субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары җитәрлек булмау сәбәпле, сайлап алынган һәм сайлап алуда җиңүчеләр дип танылган коммерциягә карамаган оешмаларның тулы күләмдә канәгатьләндерелмәгән заявкалары булган очракта, субсидия, заявкалар рейтингында элек бирелгән номерны исәпкә алып, сайлап алуны кабат үткәрмичә бүленергә мөмкин яки Вәкаләтле органның карары буенча сайлап алуда җиңүчегә (җиңүчеләргә) субсидия күләмен һәм субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечен арттыру турында тәкъдим җибәрелергә мөмкин.

5.3. Субсидия бирү турындагы килешүгә үзгәрешләр кертү түбәндәге очракларда мөмкин:

субсидия алучының (алучыларның) реквизитлары үзгәргән;

Вәкаләтле органга субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары киметелгән;

Вәкаләтле орган тарафыннан хисап финанс елында субсидия алучы (алучылар) тарафыннан субсидиянең файдаланылмый калган өлешләренә ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән.

5.4. Субсидия алучы (алучылар) кушылу, кушу яки үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, субсидия бирү турындагы килешүдә хокук варисы булып торучы юридик затны күрсәтеп, йөкләмәдә затның үзгәрүе өлешендә субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән субсидия бирү турындагы килешүгә үзгәреш кертелә.

Субсидия алучы (алучылар) бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, шулай ук субсидия алучы (алучылар) бетерелгәндә субсидия бирү турындагы килешү, берьяклы тәртиптә субсидия бирү турында килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм субсидия алучы (алучылар) тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләрне үтәү турындагы мәгълүматны чагылдырып, субсидия бирү турында килешү буенча йөкләмәләрнең үтәлеше һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында акт төзеп өзелә.

Субсидия алучы (алучылар) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүне бер яклы тәртиптә өзү рөхсәт ителми.

5.5. Субсидия Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидия алучы (алучылар) тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яисә корреспондент счетына субсидия бирү турындагы килешү нигезендә күчерелә.

5.6. Субсидия алучыга (алучыларга), шулай ук субсидия алучы (алучылар) белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән,

югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алу тыела.

5.7. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше булганда, субсидия алучы (алучылар) хисап елыннан соң киләчә торган елның 15 гыйнварына кадәр Вәкаләтле органга әлеге акчага ихтыяҗ булуны нигезли торган документлар тапшыра.

Вәкаләтле орган субсидия алучыдан (алучылардан) әлеге документларны алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 15 көн эчендә субсидия алучының (алучыларның) әлеге акчага ихтыяҗы булу турында яки аларга ихтыяҗ булмаганда әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтару хакында карар кабул итә.

Субсидия алучының (алучыларның) хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешенә ихтыяҗы булу турында Вәкаләтле органның карары булмаган очракта, субсидия алучы (алучылар) әлеге акчаны хисап елыннан соң киләчә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтарырга тиеш.

Вәкаләтле орган тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешенә субсидия алучының (алучыларның) ихтыяҗы булу турында карар кабул ителгән очракта, субсидия алучы (алучылар) финанс белән тәэмин итү чыганагы әлеге акча булган чыгымнарны әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга тотарга хокуклы.

Субсидия алучы (алучылар) тарафыннан әлеге пунктның өченче абзацында билгеләнгән субсидияне ирекле рәвештә кире кайтару срогы бозылган очракта, Вәкаләтле орган әлеге срок тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә.

VI. Субсидия бирү нәтиҗәсе һәм хисапка карата таләпләр

6.1. Субсидия бирү нәтиҗәсе – субсидия алучы (алучылар) тарафыннан бүләк комплектлары Татарстан Республикасы медицина оешмаларына илтеп бирү гамәлгә ашырыла торган елның 31 декабренә карата яңа туган балалы гаиләләрне бүләк комплектлары белән тәэмин итү өчен субсидия алучы (алучылар) тарафыннан Татарстан Республикасы медицина оешмаларына илтеп бирелгән бүләк комплектлары саны.

Субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткече субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнә.

Субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешүне бәяләү ($П_Р$) Вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$П_р = \frac{КП_{факт}}{КП_{план}} \times 100\%,$$

монда:

$КП_{факт}$ – яңа туган балалы гаиләләрне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы медицина оешмаларына фактта илтеп бирелгән бүләк комплектлары саны;

$КП_{план}$ – агымдагы елда яңа туган балалы гаиләләрне тәэмин итү өчен бүләк комплектларының план саны.

6.2. Субсидия алучы (алучылар) хисап елының I – III кварталлары өчен, хисап кварталыннан соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, хисап елының IV кварталы өчен, хисап елыннан соң килә торган елның 10 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән субсидияләр бирү турында килешүләрнең бертип формаларына теркәлә торган формалар буенча «Электрон бюджет» системасы аша, арта бара торган йомгак белән формалаштырыла, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүне раслый торган документларны һәм материалларны теркәп, субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм арта бара торган йомгак белән формалаштырыла торган, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Вәкаләтле орган субсидия бирү турындагы килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык (кирәк булганда) бирү срокларын һәм формаларын билгеләргә хокуклы.

6.3. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 6.2 пунктында каралган субсидия алучы (алучылар) тарафыннан тапшырылган хисапларны «Электрон бюджет» системасында аларны алган датадан биш эш көне эчендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

Хисапларны карап тикшерү йомгаклары буенча Вәкаләтле орган, аларны «Электрон бюджет» системасыннан алган көннән алып җиде эш көненнән дә соңга калмыйча, хисапларны кабул итү яки кабул итмәү турында карар кабул итә.

Хисапларны кабул итмәү өчен нигезләр:

хисапта аларны бирү өчен хисапларның бертип формаларында каралган белешмәләр тулы күләмдә булмау;

хисапта бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

6.4. Вәкаләтле органга тапшырыла торган, әлеге Тәртипнең 6.2. пунктында күрсәтелгән хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучыга (алучыларга) йөкләнә.

## VI. Субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру турында таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

7.1. Вәкаләтле орган субсидия алучының (алучыларның) субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

7.2. Субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау

Вәкаләтле орган тарафыннан нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.

7.3. Субсидия, Вәкаләтле органның һәм (яки) дәүләт финанс контроле органнарының тиешле таләбен алган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар һәм тәртип бозылган очракта, шул исәптән вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булганда;

файдаланылмый калган өлеш күләмендә;

субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелмәгән күрсәткече өчен пропорциональ рәвештә билгеләнә торган күләмдә – әлеге Тәртипнең 6.1 пункты нигезендә субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткеченә ирешмәгән очракта.

7.4. Субсдия алучы (алучылар) тарафыннан әлеге Тәртипнең 7.3 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда, Вәкаләтле орган субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

Субсидия алучы (алучылар), әгәр субсидияләр бирү турындагы килешүдә билгеләнгән срокларда субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешмәгән очракта, кичектерелгән һәр көн өчен кире кайтарылырга тиешле субсидия суммасыннан Россия Федерациясе Үзәк банкының пеня исәпләнә башлау датасына гамәлдә булган төп ставкасыннан бер бөтен меңнән өч йөз алтмыш күләмендә пеня (субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүнең план буенча датасыннан соң килә торган беренче көннән субсидияне кире кайтару көненә кадәр) түли.

---